Казан  шәһәре Мәскәү районы
аерым фәннәрне  тирәнтен өйрәнүле
65нче гомуми урта  белем бирү мәктәбе

# Тәрҗемә. Сөйләм культурасы

Башкарды: татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Аглиуллова Лилия Җәүдәтовна

Казан, 2018

**Эчтәлек**

1. Кереш____________________3 б.
2. Төп өлеш__________________3-5 б.
3. Йомгаклау_________________5 б.
4. Әдәбият исемлеге___________6 б.

## Кереш.

Тәрҗемә төрле милләт халыкларының аралашуына, аңлашуына , рухи хәзинәләр алмашуына хезмәт итә. Төрле телләрдә сөйләшүче халыкларның хезмәттәшлеге никадәр элегрәк башланган булса, тәрҗемә тарихы да шулкадәр элекке чорлардан, борынгы заманнардан ук килә.Безнең көннәргә кадәр сакланып калган документлар тәрҗемәнең борынгы греклар тормышында да шактый зур роль уйнаганлыгын күрсәтә. Хәзерге фән-техника, мәдәният дөнья күләмендә югары үсеш алган заманда тәрҗемәнең әһәмияте гаять зур. Аның роле бүгенге бөтен дөнья буйлап җәелә барган глобальләшү чорында тагын да арта төшә.

## Төп өлеш.

Тәрҗемә эшенең аеруча киң колач җәйгән урыны- күпмилләтле Россия Федерациясе . Тәрҗемә- илебездә халыклар дуслыгын, аларның туганнарча хезмәттәшлеген ныгытучы иң әһәмиятле чараларның берсе.

Хәзерге вакытта тәрҗемә өч төрле формада: язмача, телдән һәм машина ярдәмендә, аерым алганда, рус теленнән татар теленә, нигездә,язмача башкарыла.

Бер телдән икенче телгә күчерелә торган материалның характерына карап, тәрҗемә күптөрле була. Бездә матур әдәбият та , фәнни-техник, политик әдәбият та, дәреслекләр дә, төрле документлар, газета-журнал материаллары да, радио- телевидение тапшырулары, кинофильмнар да тәрҗемә ителә.

Тәрҗемә нинди генә формада һәм нинди генә төрле булмасын, аның максаты бер була- бер телдәге текст яисә хәбәрне икенче телгә мөмкин кадәр тулы һәм төгәл итеп күчерү.Ягъни тәрҗемә ул-бер телдә әйтелгән яки язылган фикерне башка тел чаралары белән төгәл һәм тулы итеп белдерү.

Тәрҗемә теориясе әдәбият белеме белән дә нык бәйләнгән. Матур әдәбият тәрҗемәсен анализлаганда, аның сәнгатьлелек ягыннан оригиналга тиң булу-булмавын ачыклау, оригиналдагы сурәтләү чараларының тәрҗемәдә ничек бирелүен һ.б. шундый мәсьәләләрне хәл иткәндә, һичшиксез, әдәбият белеменә таянырга туры килә.

Тәрҗемәгә анализ ясап, аның оригиналга тиң булу- булмау мәсьәләсен хәл иткәндә , әсәрдә сурәтләнгән аерым фактларны өйрәнергә, ачыкларга туры килә. Ул фактлар, әсәрнең характерына карап, аерым халыкларның тарихына,көнкүрешенә, сәяси вакыйгаларга, төгәл фәннәргә карый. Димәк, тәрҗемә теориясе тарих, этнография, философия, физика, математика һ.б. төрле фәннәр белән дә бәйләнешкә керә.

Тәрҗемә принципларының беренчесе һәм иң әһәмиятлесе-оригиналның мәгънәсен , эчтәлеген, идеясын тулы бирү.Эчтәлек формага караганда әһәмиятлерәк булганга, ягъни беренче дәрәҗәдә торганга, оригиналның эчтәлеген, мәгънәсен бирү- тәрҗемәнең төп бурычы.Башка таләпләр шушы төп бурычны үтәү җирлегендә килеп чыгалар.

Мәгънәне, эчтәлекне тулы бирү принцибы тәрҗемә төгәл булырга тиеш дигән таләп белән аерылгысыз бәйләнгән.Тәрҗемә төгәл булмаса, анда оригиналның мәгънәсе тулы бирелә алмый һәм, киресенчә, оригиналның мәгънәсе тулы бирелмәсә, тәрҗемәнең төгәл булуы мөмкин түгел.

Оригиналга тиң тәрҗемәгә иҗади эшләгәндә генә ирешергә мөмкин. Машина тәрҗемәсеннән кала һәртөрле тәрҗемә - иҗади процесс. Тәрҗемәченең бурычы - күптөрле вариантларның берсен эчтәлеге, формасы буенча оригиналга мөмкин кадәр якынрагын эзләп табу. Әнә шул эзләү иҗадилыкны тәшкил итә дә инде.

Тәрҗемәнең төп принциплары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Тәрҗемәдә оригиналның эчтәлеген, мәгънәсен, идеясен максималь тулы, төгәл бирү зарури.

Тәрҗемәдә оригиналның форма үзенчәлекләре, автор стиле, сәнгатьлелек, милли үзенчәлеге мөмкин булганча тулы гәүдәләнергә тиеш.

Тәрҗемә оригиналга стиле буенча һәм эстетик яктан тиң булганда гына матур була.

Хәрефкә- хәреф тәрҗемә булырга тиеш түгел.

Тәрҗемә- иҗади процесс.

Тулы кыйммәтле тәрҗемәгә ирешүнең төп һәм беренче шарты - тәрҗемәченең ике телне дә - оригинал һәм тәрҗемә телләрен бик яхшы белергә тиешлеге.

Ике телдә эш итүче кеше ул телләрнең икесен дә яхшы белмәсә һәм сөйләм культурасына, бер телнең икенче телгә тискәре тәэсирен булдырмаслык көчкә, сәләткә ия булмаса, телләрнең берсенә генә хас үзенчәлекләрнең икенче телгә күчүенә һәм нәтиҗәдә ул телнең бозылуына сәбәпче була.

## Йомгаклау.

Киләчәктә безнең алдыбызда түбәндәгечләр бурычлар тора: ике телдәге сүзтезмәләр нисбәтен өйрәнү, бүгенге көндә телебездә шактый зур урын алып торган, әмма шул ук вакытта табигый булмаган, ясалма әйтелмәләрне, җөмләләрне анализлау, аларның барлыкка килү механизмын күзәтү, сәбәпләрен ачыклау һәм, хаталарны төзәтеп, алар урынына татарча дөрес вариантлар тәкъдим итү.

Әдәбият исемлеге


1. Р.Юсупов Тәрҗемә һәм сөйләм культурасы. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2008.
2. Р.Р. Җамалетдинов Тел һәм мәдәният. Татар лингвокультурологиясе нигезләре. – Казан: “Мәгариф” нәшрияты, 2006.
3. А.В.Федоров Основы общей теории перевода. М. : Высшая школа, 1968